СОВЕТ
Салаушского сельского поселения
Агрызского муниципального района
Республики Татарстан

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Салагыш авыл җирлеге
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24.02.2025 Салагыш авылы № 59-2

Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» 23.05.2022 елның 18-2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» 23.05.2022 елның 18-2 номерлы карарына кушымта итеп бирелә торган үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлегенең махсус бирелгән мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә.
3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы М.М.Мөхәммәдиев

Совет Салаушского сельского поселения
Салагыш авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002491

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль
районы Салагыш авыл җирлеге Советының
24.02.2025 № 59-2 карары белән расланды

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлеге Советының 23.05.2022 елның 18-2 номерлы «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» карарына кертелә торган

ҮЗГӘРЕШЛӘР

1. 1 бүлекнең 1.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4-5 абзацлар өстәргә:
«рөхсәт бирү документларындагы таләпләрне үтәү (гамәлгә ашыру);

Россия Федерациясе законнары нигезендә үтәлергә тиешле документлар таләпләрен үтәү;»;

2. 1 бүлек 1.2 пунктының 2 абзацында « , Кагыйдәләр нигезендә төзекләндерүне оештыру» сүзләрен төшереп калдырырга.;

3. 3 бүлекнең 3.5.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.1. Профилактик визит контрольдә тотылучы затның эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча инспектор тарафыннан профилактик әңгәмә рәвешендә йә видео-конференц-элемтә яисә «Инспектор» мобиль кушымтасы ярдәмендә үткәрелә.

Профилактик визит барышында контрольдә тотылучы зат үз эшчәнлегенә йә аңа караган контроль объектларына куела торган мәҗбүри таләпләр, аларның хәвеф-хәтәр критерийларына туры килүе, хәвеф-хәтәр категориясен киметүнең тәкъдим ителә торган ысуллары, төрләре, эчтәлеге һәм контроль объектына карата аны хәвеф-хәтәрнең тиешле категориясенә кертүдән чыгып үткәрелә торган чараларның интенсивлыгы турында хәбәр ителә, ә инспектор контроль объекты белән танышу, контроль объектларын хәвеф-хәтәр категорияләренә кертү өчен кирәкле белешмәләр җыю, һәм контрольдә тотылучы затның мәҗбүри таләпләрне үтәү дәрәҗәсен бәяли.

Профилактик визит контроль (күзәтчелек) органы инициативасы буенча (мәҗбүри профилактик визит) яисә контрольдә тотылучы зат инициативасы буенча үткәрелә.

Профилактик визит үткәрү йомгаклары буенча контроль объектына «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 31.07.2020 елның 248-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясындагы 6 һәм 7 өлешләре нигезендә мәҗбүри таләпләрне үтәү дәрәҗәсен ачык бәяләү бирелергә мөмкин.»;

4. 4 бүлекнең 4.1.5 пунктының 2 абзацында «мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү, урынга барып тикшерү» сүзләрен «үзара хезмәттәшлексез контроль (күзәтчелек) чаралары» сүзләренә алмаштырырга.;

5. 4.5.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә:
«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 31.07.2020 елның 248-ФЗ номерлы Федераль законның 1

өлешендәге 3, 4, 6, 8 пунктлары, 57 статьясындагы 3 өлеше һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә аны үткәрү очракларыннан тыш»;.

6. 4.5.6 пунктының 2 абзацына сүзләр өстәргә:

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты нигез булган һәм микропредприятие өчен кырык сәгатьтән артык дәвам итә алмаган күчмә тикшерүдән тыш.»;

7. 4.5.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5.7. Күчмә тикшерү барышында мөмкин булган контроль гамәлләр исемлеге:

1) карау;
2) тикшерү;
3) сораштыру;
4) язма аңлатмалар алу;
5) документларны таләп итү;
6) пробалар (үрнәкләр) алу;
7) инструменталь тикшерү;
8) сынау;
9) экспертиза;
10) тәҗрибә.»;

8. 4.6.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле д) пунктчасы өстәргә:

«д) инструменталь тикшерү.»

9. 4.6.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6.5. Рейд тикшерүе барышында мөмкин булган контроль гамәлләр исемлеге:

1) карау;
2) тикшерү;
3) сораштыру;
4) язма аңлатмалар алу;
5) документларны таләп итү;
6) пробалар (үрнәкләр) алу;
7) инструменталь тикшерү;
8) сынау;
9) экспертиза;
10) тәҗрибә.»

10. 4.6.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6.8. Рейд тикшерүе прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин, моңа «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 1 өлешендәге 3, 4, 6, 8 пунктлары, 57 статьясындагы 3 өлеше һәм 66 статьясындагы 12 өлеше нигезендә үткәрелгән очраклар керми.;

11. 4.8.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.8.4. Урынга барып тикшерү нәтиҗәләре буенча «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында каралган карар кабул ителә алмый, моңа контроль төре турында Федераль законда билгеләнгән очраклар керми.»

12. 4.9.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 5) пунктча өстәргә:
«5) контроль (күзәтчелек) чарасы актын рәсмиләштергәннән соң контрольдә тотылучы затка мәҗбүри таләпләрне ачыкланган бозуларны бетерү турында, аларны бетерүнең нигезле срокларын, шулай ук Контроль төре турындагы Федераль законда каралган башка чараларны күрсәтеп, күрсәтмә бирергә.»

13. 4 нче бүлекнең 4.4.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4.4.10. Планнан тыш документар тикшерү «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 31.07.2020 елның 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4, 6, 8 пунктлары нигезендә прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин.»;

14. «Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында үтәлеше билгеләнә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге» кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль
районының Салагыш авыл җирлеге Советының
24.02.2025 № 59-2 карары белән расланды

**Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында үтәлеше билгеләнә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге**

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен бозу билгеләрен кварталга 2 тапкырдан артык ачыклау.

2. Дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, юридик затлардан, иҗтимагый берләшмәләрдән, гражданнардан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен бозуның һәм закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычы барлыгын раслый торган гамәлләр (гамәл кылмау) турында контроль органына кварталга 2 тапкырдан артык белешмәләр керү.

3. Муниципаль контроль органында контрольдә тотылучы заттан бирелгән мәҗбүри таләпләрне ачыкланган бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәнең билгеләнгән вакытта үтәлеше турында мәгълүмат булмау.».